КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 октябрь г.Казань № 1252

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел,

6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче, 2022 ел, 16 ноябрь, 1218 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче, 2023 ел, 14 апрель, 462 нче, 2023 ел, 05 август, 946 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыру (01.06.15);»;

3.2 пунктның унбишенче абзацында «01.03» саннарын «02.03» саннарына алмаштырырга;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчада:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәҗбүри таләпләр бозылу аркасында әйләнә-тирә мохиткә салынган зыянны каплау турында дәгъвалар бирә;»;

унҗиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.3 пунктчада:

дүртенче абзацта «ташлауларны киметүне» сүзләрен «ташлауларны киметүне» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгарып ташлауларны киметү» сүзләрен «пычраткыч матдәләр чыгарып ташлауларны киметү» сүзләренә алмаштырырга, «хәрәкәтчән» сүзен «күчмә» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү максатларында торак пунктларда, ял һәм туризм урыннарында, махсус сакланылучы территорияләрдә транспорт чараларының хәрәкәт итүенә чикләүләр кертә;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

уникенче абзацта «зарарлы (пычраткыч) матдәләр» сүзләрен «пычраткыч матдәләр» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

уналтынчы абзацта «зарарлы (пычраткыч) матдәләр» сүзләрен «пычраткыч матдәләр» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.7 пунктчада:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең территориаль органы тәкъдиме буенча атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларның мөмкин нормативларына этаплап ирешү срокларын раслый;»;

бишенче абзацта «ташлауларны киметүне» сүзләрен «ташлауларны киметүне» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.8 пунктчаның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.9 пунктчаның җиденче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2006 елга Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм минераль-чимал базасын торгызу территориаль программасын раслау турында» 2006 ел, 08 сентябрь, 457 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2006 елга Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм минераль-чимал базасын торгызу территориаль программасын раслау турында» 2006 ел, 08 сентябрь, 457 нче карары белән расланган 2006 елга Татарстан Республикасының җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм минераль-чимал базасын торгызу территориаль программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 7 декабрь, 777 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгы
турындагы нигезләмәгә
кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 6 октябрь, 1252 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы оешмалар белән хезмәттәшлек итә торган икътисадый эшчәнлек төрләре исемлеге

| ИЭТГК буенча икътисадый эшчәнлек төренең коды* | Икътисадый эшчәнлек төренең аталышы |
|---|---|
| В бүлеге. Файдалы казылмалар чыгару | |
| 08 | Башка файдалы казылмаларны чыгару |
| М бүлеге. Һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек | |
| 71.12.3 | Җир асты байлыкларын өйрәнү һәм минераль-чимал базасын торгызу өлкәсендә геологик-разведка, геофизик һәм геохимик эшләр |
| 71.12.4. | Геодезия һәм картографик эшчәнлеге |
| 71.12.42 | Топографик карталар һәм планнар төзүдән тыш, картографик эшчәнлек |
| 71.12.5 | Гидрометеорология һәм аның белән чиктәш өлкәләр өлкәсендәге эшчәнлек, әйләнә-тирә мохитнең торышын мониторинглау, аның пычрануы |
| 71.12.52 | Гелиофизик һәм геофизик эшләр башкару |
| 71.12.53 | Физик һәм юридик затлар өчен әйләнә-тирә мохитнең пычрануын мониторинглау эшчәнлеге |
| 71.12.57 | Метеорологик һәм геофизик процессларга һәм күренешләргә актив йогынты ясауга бәйле эшчәнлек |
| 71.12.62. | Метрология өлкәсендәге эшчәнлек |

ИЭТГК – Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы.